# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Хәйрия эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья.** «Хәйрия эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, №7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15 статьяның 2 өлешендә «һәм Татарстан Республикасының» сүзләрен төшереп калдырырга, «шартнамәләрендә» сүзеннән соң «һәм халыкара, тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит илләрнең административ-территория берәмлекләре һәм чит илләрнең дәүләт хакимияте органнары арасында федераль закон нигезендә төзелгән килешүләр» сүзләрен өстәргә;

23 статьяның 1 өлешендә «һәм Татарстан Республикасының» сүзләрен төшереп калдырырга, «шартнамәләрендә» сүзеннән соң «һәм халыкара, тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит илләрнең административ-территория берәмлекләре һәм чит илләрнең дәүләт хакимияте органнары арасында федераль закон нигезендә төзелгән килешүләр» сүзләрен өстәргә;

24 статьяда «Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре» сүзләрен «Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре һәм халыкара, тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит илләрнең административ-территория берәмлекләре һәм чит илләрнең дәүләт хакимияте органнары арасында федераль закон нигезендә төзелгән килешүләр» сүзләренә алыштырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 28 марты
№ 705